| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2021 Казан ш. № 373-35/тко-2021

«Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2022-2024 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

3. «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2022-2024 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

4. «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә иректе файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2021 № 373-35/тко-2021
карарына 1 нче кушымта

«Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2022-2024 елларга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Чистай муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 95,06 | 103,13 | 100,05 | 100,05 | 100,05 | 104,80 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2021 № 373-35/тко-2021
карарына 2 нче кушымта

## «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2022-2024 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешма исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2022 | 18543,00 | 1 | 0 | 0,18 |
| | | 2023 | 19091,87 | 1 | 0 | 0,18 |
| | | 2024 | 19656,99 | 1 | 0 | 0,18 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге